Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXIV-24**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 1 нче марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга милеккә бушлай җир кишәрлекләре бирү (тапшыру) турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, 2022 елның 25 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга милеккә бушлай җир кишәрлекләре бирү (тапшыру) турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә даими яшәүче унсигез яшькә җитмәгән өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бушлай милеккә бирелә (тапшырыла) торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре турында” XIV-2 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә бирү (тапшыру) Тәртибе турында” XIV-3 номерлы карарын;

- “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә бирү (тапшыру) Тәртибе турында” 2012 елның 27 гыйнварындагы XIV-3 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 12 июлендәге XVIII-13 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирүне (тапшыруны) җайга сала торган аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” XXII-3 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 1 апрелендәге “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе

нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә бирү (тапшыру) тәртибе турында” 2012 елның 27 гыйнварындагы XIV-3 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында” XLI-10 номерлы карарын.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2023 елның 1 нче марты
XXXIV-24 номерлы карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга милеккә бушлай җир кишәрлекләре бирү (тапшыру) турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

1.2. Муниципаль милектәге җирләрдән, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлекләре җир кишәрлеген милеккә бирү турында гариза бирелгән датага Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче өч һәм аннан күбрәк баласы, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынган һәм тәрбиягә алынганнары (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән яисә алар унсигез яшькә җиткәнчегә кадәр гамәлгә ашырыла торган) булган гражданнарга бушлай бирелә (тапшырыла):

-торглар уздырмыйча, индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен объектлар урнаштыру урыннарын алдан килештермичә, әгәр мондый гражданнар Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торсалар – 0,06 гектардан 0,20 гектарга кадәр мәйдан;

- алар милкендә элек бирелгән җир кишәрлегендә урнашкан торак йорт булган, Федераль закон нигезендә мондый җир кишәрлеге хосусый милеккә бирелә алмаган очраклардан гайре – элек бирелгән җир кишәрлекләре күләмнәрендә, әмма 0,20 гектардан артык булмаган.

Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар дигәннән үзара никахта торучы яисә никахта тормаучы, әмма бергә яшәүче ата-аналар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) яки бер ата-ана (уллыкка алучы, опекун, попечитель) (алга таба - ата-аналар, бер ата-ана) составындагы күпбалалы гаилә, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынган һәм тәрбиягә алынганнары (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән яисә алар унсигез яшькә җиткәнчегә кадәр гамәлгә ашырыла торган) булган җир кишәрлеген милеккә бирү турында гариза бирелгән датага даими яшәүчеләр аңлашыла. Шул ук вакытта күпбалалы гаилә составына никахта тормаучы ата-ана да керә, аларның кимендә өч уртак баласы булган очракта. Чит ил гражданнары,

гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук әлеге пунктта каралган нигезләрдә җир кишәрлеген бирү (тапшыру) хокукын гамәлгә ашыручы гражданнар күпбалалы гаилә составына кертелми.

Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар әлеге пунктның икенче абзацында каралган җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү турындагы таләпкә туры килә дип санала, әгәр ата-ананың берсе яисә бердәнбер ата-ана җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәсә.

1.3. Җир кишәрлекләре гражданнарга һәм балаларга уртак өлешле милеккә тигез өлешләрдә бирелә.

Ата-ананың берсенең җир кишәрлегенә гомуми өлеш милке хокукында өлеш алудан язма рәвештә баш тарткан яисә аны закон көченә кергән суд карары белән билгесез дип таныган очракта җир кишәрлеге икенче ата-ананың һәм балаларның тигез өлешләрдә гомуми өлешле милкенә бирелә (тапшырыла).

1.4. Гражданнар шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә шундый гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен аларга тапшыру өчен җир кишәрлеге бирү хокукларын бер тапкыр тормышка ашыра алалар.

1.5. Гражданнар милкенә җир кишәрлекләре бирү турында карар кабул иткәндә, гариза тапшырылганнан соң әлеге гражданнарның ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән, уллыкка алу яисә попечительлек туктатылган балалары исәпкә алынмый.

1.6. Җир кишәрлекләре бирү җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, җир төзелеше, шәһәр төзелеше һәм проект документлары нигезендә башкарыла.

1.7. Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр яисә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче 2 п. күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирү белән кызыксынучы гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр яисә авыл җирлеге чикләрендә, район Советы карары белән билгеләнә торган очракларда, әлеге муниципаль район составындагы башка җирлек чикләрендә бирелә.

1.8. Торак йорт төзү өчен гражданга җир кишәрлеген түләүсез бирү турындагы карар җир кишәрлеге кадастр исәбенә куелган очракта гына кабул ителергә мөмкин, җир кишәрлеге чикләре тасвирланган һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланган очракта гына кабул ителергә мөмкин.

1.9. Нигезләмәдә күрсәтелгән гражданнарга индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре исемлекләре (алга таба - җир кишәрлекләре исемлекләре) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - вәкаләтле орган) күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматлары нигезендә һәм әлеге җир кишәрлекләрен алуга хокукы булган гражданнар исемлекләреннән чыгып билгеләнә торган ихтыяҗны исәпкә алып төзелә.

Җир кишәрлекләре исемлекләре аларны бирү максатларына туры китереп, вәкаләтле орган тарафыннан төзелә, раслана һәм “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш (алга таба - "Интернет" челтәре).

## 2. Гаризалар кабул итү, аларны карау һәм карарлар кабул итү тәртибе

2.1. Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен җир кишәрлекләре бирү белән кызыксынучы гражданнар вәкаләтле органга җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналар төрле муниципаль районнар (шәһәр округлары) территориясендә даими яшәп торганда җир кишәрлеге бирү турында гариза ата-аналарның берсен сайлап алу буенча даими яшәү урыны буенча бирелә. Гариза формасы башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

2.2. Индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул итү өчен гариза биргәннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча түбәндәге документлар тапшырыла:

1) гариза бирүче паспорты;

2) башка ата-ананың паспорты (әгәр ата-аналар никахта булса яки никахта тормаса, ләкин бергә яшәгән очракта);

3) балаларның туу турындагы таныклыклары, шулай ук ундүрт яшькә җиткән балаларның паспортлары;

4) баланы уллыкка алуны билгеләү турында суд карары (бала туу турындагы таныклыкта уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан гайре);

5) опекун яисә попечитель билгеләү турында опека һәм попечительлек органы акты (опека яисә попечительлек билгеләнгән очракта);

6) опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә (шартнамә буенча опека яисә попечительлек гамәлгә ашырылган очракта);

7) никахлашу турында таныклык (ата-ана никахта торган очракта);

8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинада мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;

9) җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүче паспортында җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча аны теркәү турында тамга булмаган очракта).

Әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документ, әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

2.3. Гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчене индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык (алга таба - исемлекләр) алып бару өчен һәм мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлеген

алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул итә һәм уникаль хисап номерын тапшыра.

Исемлекләрне төзү һәм алып бару җир кишәрлекләрен бирү максатларына туры китереп, орган тарафыннан аерым башкарыла. Гражданнарның чиратлылыгы гариза бирү датасы һәм вакыты буенча билгеләнә. Гражданнарның уникаль исәпкә алу номерлары исемлекләре, чиратын күрсәтеп, "Интернет" челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла һәм алар гражданнарны исемлекләргә кертү һәм аларга җир кишәрлекләре бирү буенча даими яңартылырга тиеш.

2.4. Гарызнамәче (гариза бирүче) тарафыннан Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган документлар яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан яисә вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән документлар тапшырылмаган очракта, гариза бирүченең җир кишәрлеге алуга хокукын расламасалар, шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны җир кишәрлеге), үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен вәкаләтле орган исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Гражданнарга аларны исемлеккә кертүдән баш тарту турында хәбәр итү вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча заказлы хат белән тапшыру турында хәбәрнамә яисә аларга имза куйдырып тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.5. Гражданнарга Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирү чират тәртибендә башкарыла.

2.6. Вәкаләтле орган җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәрү урынын, датасын һәм вакытын билгели һәм гражданнарны әлеге процедурада катнашу өчен аларның чираты һәм формалаштырылган җир кишәрлекләре санына туры китереп билгели.

Вәкаләтле орган тарафыннан җир кишәрлеген сайлау процедурасын үткәргән көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча, аны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында заказлы хат белән тапшыру турында хәбәрнамә, телеграмма яисә аларга имза куйдырып тапшыру юлы белән хәбәр ителә.

Җир кишәрлеген сайлау гражданнар исемлегеннән аларның чираты нигезендә башкарыла һәм гариза бирүче һәм вәкаләтле орган вәкиле имзалаган акт белән рәсмиләштерелә.

2.7. Җир кишәрлеге бирү турындагы карар Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән акт нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан имзаланганнан соң 14 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

2.8. Вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирүдә кызыксынган гражданнарны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында түбәндәге очракта карар кабул итә:

1) гражданнарга әлеге Нигезләмәнең 1.2 пункты нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү;

2) гражданнарның әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән таләпләргә түбәндәгеләр аркасында туры килмәве:

а) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;

б) Татарстан Республикасыннан даими яшәү урынына китү;

в) ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, уллыкка алуны юкка чыгару, опеканы яисә попечительлекне туктату;

г) ата-ананың (ата-ананың) законсыз гамәлләре (гамәл кылмаулары) нәтиҗәсендә бала (балалар) вафат булу;

д) социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;

3) гражданнар тарафыннан аларны исемлектән төшереп калдыру турында гариза бирү;

4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның җир кишәрлеген сайлаудан өч тапкыр баш тартуы яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, яисә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм җир кишәрлеген тулаем алганда сайлау процедурасына килмәү очракларының саны өчкә тигез булу;

5) гражданнар исемлекләргә кертелгән документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган һәм гражданнарның әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында дәлилле торган мәгълүматларның ачыклануы.

Гражданнарга исемлекләрдән төшереп калдыру һәм җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында хәбәр итү вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча заказлы хат белән яисә аларга язма хәбәрне кул куйдырып бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.9. Үз милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен тапшыру белән кызыксынган гражданнар әлеге җир кишәрлеген аларга тапшыру турында гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәләр. Гариза формасы башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

Гаризаны язмача яки электрон документ формасында гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып вәкаләтле органга яки күпфункцияле үзәк аша тапшырырга мөмкин.

10. Әлеге Кодексның 32 маддәсендәге 3 пунктында күрсәтелгән гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлеген әлеге маддәнең 2 пунктындагы 1-7 пунктчаларында каралган документлар белән бер үк вакытта тапшыру турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар кирәк:

1) тапшырыла торган җир кишәрлегендә урнашкан торак йортка күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) тапшырыла торган җир кишәрлегенә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3) торак йортка хокук билгели торган документ (әгәр әлеге торак йортка милек хокукы күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса);

4) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ (әгәр әлеге җир кишәрлегенә хокук күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса). Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр мөрәҗәгать итүче аларны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.

11. Җир кишәрлекләрен алар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен тапшыруда кызыксынучы гражданнар милкенә түләүсез тапшыру

алар вәкаләтле органга гариза биргән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла һәм әлеге орган карары белән рәсмиләштерелә.

12. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган документлар тапшырмаган очракта яисә мөрәҗәгать итүче яисә вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган документлар мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген тапшыруга хокукын расламасалар, вәкаләтле орган җир кишәрлеген тапшырудан баш тарту турында карар кабул итә.

Гражданнарга җир кишәрлеген тапшырудан баш тарту турында хәбәр итү вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча заказлы хат белән яисә хәбәр бирү турында кул куйдырып гамәлгә ашырыла.

13. Вәкаләтле орган милкенә җир кишәрлекләре бирелгән (тапшырылган) гражданнар реестрын алып бара.

14. Әлеге Нигезләмәнең 1 маддәсендәге 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү (тапшыру) турында мәгълүмат социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) “Дәүләт социаль ярдәме турында” 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.